ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

20.07.2020 ел Баулы шәһәре №144

Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2018 елның 11 декабрендәге 454 номерлы карары (2020 елның 4 февралендәге 21 номерлы, 2020 елның 6 маендагы 98нче номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) белән расланган Баулы муниципаль районы территориясендә Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының статьяларында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлегенә өстәмәләр кертү турында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2018 елның 11 декабрендәге 454 номерлы карары (Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 04 февралендәге 21 номерлы, 2020 елның 06 маендагы 98нче номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) белән расланган Баулы муниципаль районы территориясендә Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының статьяларында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлегенә түбәндәге өстәмәләр кертергә:

«Татарстан Республикасы Административ хокук бозулар кодексының 3.10. статьясы юлында икенче баганада икенче абзацтан соң түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

| | |
|---|---|
| «Татарстан Республикасы Административ хокук бозулар кодексының 3.10. статьясы Татарстан Республикасы территориясендә су объектларында кешеләрнең гомерен саклау кагыйдәләрен бозу | - Баулы муниципаль районы башкарма комитетының икътисад һәм территориаль үсеш бүлегенең баш һәм әйдәүче белгече;<br>- Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге баш белгече;<br>- Баулы муниципаль районы башкарма комитетының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау бүлегенең әйдәп баручы белгече;<br>- Баулы муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге баш белгече.”. |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров